ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2019 г. с. Муслюмово № 465

**Татарстан Республикасы Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатында хәрби исәптә торырга тиеш, ләкин тормаган 2003 елда туган һәм өлкән яшьтәге гражданнарны хәрби исәпкә куюны әзерләү һәм үткәрү турында**

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә, **КАРАР БИРӘМ:**

2020 елның 1 гыйнварыннан 31 мартына кадәр Мөслим муниципаль районы территориясендә яшәүче (3 айдан артык), төрле сәбәпләр аркасында билгеләнгән срокта хәрби исәпкә куелмаган 2003 елгы ир-атлар һәм хәрби хезмәткә алынучы өлкән яшьтәге гражданнарны хәрби исәпкә алуга башлангыч әзерлек үткәрергә.

1. Гражданнарны хәрби исәпкә алу комиссия составын расларга (1 нче кушымта нигезендә).

2. Гражданнарны хәрби исәпкә кую буенча комиссиянең эш тәртибен билгеләргә:

2.1. 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 мартына кадәр, якшәмбедән тыш, һәр көнне 8.00-16.00 сәгатьләрдә, шимбә көнне 08.00-14.00 сәгатьләрдә;

2.2. Эш көне дәвамында таныклanучылар саны 50 кешедән артмаска тиеш.

3. Предприятие, оешма һәм уку учреждениеләре җитәкчеләренә, авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

3.1. 2019 елның 1 ноябренә кадәр Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатына 2003 елда туган яшүсмерләр исемлеген тапшырырга, алар булмаган очракта әлеге категория гражданнары саналмый дип хәбәр итәргә;

3.2. Башлангыч хәрби исәпкә кую өчен 2003 елда туган гражданнарның шәхси повесткалаында күрсәтелгән барлык кирәкле документлар белән Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатына килүен тәэмин итәргә;

3.3. Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатында билгеләнгән срокларда гражданнарны авыл җирлекләре секретарьлары, ОВС укытучылары, физруклар һәм шәфкать туташлары белән берлектә комиссиягә китерүне оешкан төстә алып барырга;

3.4. 2020 елның 22 гыйнварыннан 2003 елда туган һәм өлкән яшьтәге егетләрне эшкә, укуга бары тик хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданин таныклыгы, Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариаты тамгасы булган очракта гына кабул итәргә кирәк. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле граждан таныклыгы булмаган барлык егетләр турында кичекмәстән

Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссариатына хәбәр итәргә һәм егетләрне хәрби исәпкә алу бүлекчәсенә җибәрергә.

4. «Мөслим РҮХ» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибына:

4.1. 2003 елда туган гражданнарны башлангыч хәрби исәпкә кую буенча медицина комиссиясе хезмәткәрләрен медицина белән тәэмин итүне оештырырга;

4.2. Башлангыч хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарга медицина тикшеренүен уздыру һәм тикшерү актларын сыйфатлы төзү өчен кирәкле санда табиб - белгечләр һәм урта медицина персоналын (1,2,3 кушымта) бүлеп бирергә, хәрби хезмәткә чакырылучылардан анализлар кабул итүне оештырырга, башлангыч хәрби исәпкә кую комиссиясе бәяләмәсе буенча дәвалауга мохтаҗ булган хәрби хезмәткә чакырылучы егетләр белән нәтиҗәле дәвалау эшен оештырырга;

4.3. Хәрби хезмәткә чакырылучыларны стационар тикшерү өчен район үзәк хастаханәсендә 1-2 урын бүлеп бирергә. Әлеге максат өчен иң җаваплы табиб - белгечләрне беркетергә һәм хәрби хезмәткә чакырылучыларны билгеләнгән вакытта тулысынча һәм сыйфатлы тикшерүне тәэмин итәргә.

5. Полиция җитәкчесенә:

5.1 Башлангыч хәрби исәпкә куелу чорында Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссары карамагында хәрби исәпкә куюдан качучы гражданнарны бергәләп эзләү өчен бер полиция хезмәткәрен җибәрергә;

5.2. Хәрби исәптән качучы һәм законлы нигез булган очракта тоткарлау өчен гражданнарны эзләргә;

5.3. Башлангыч хәрби исәпкә куелудан качучы гражданнарны эзләү һәм тоткарлау эшен катгый контрольгә алырга;

5.4. Хәрби хезмәткә башлангыч әзерлек буенча комиссия эшләгән көннәрдә чакыру пунктында җәмәгать тәртибен тәэмин итү өчен милициянең дежур хезмәткәрен бүлеп бирергә.

6. Башлангыч хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарда һөнәри психологик сайлап алуны уздыру өчен, штаттан тыш профотбор төркемен (4 нче кушымта) төзергә һәм аңа йөкләргә:

6.1. Гражданнарны хәрби-исәпкә кую белгечлеге алу, контракт буенча хәрби хезмәткә керү, хәрби әзерлек алып баручы укытучыларга консультация бирү, һөнәри белем бирүче хәрби-мәгариф учреждениеләренә керү өчен кандидатларны алдан сайлап алырга;

6.2. Хәрби - хисап белгечлеге буенча әзерлек өчен кандидатларның һөнәри яраклылыгын тикшерергә;

6.3. Нерв - психик тотрыксызлыгы булган гражданнарны ачыкларга;

6.4. Һөнәри психологик сайлап алу буенча үткәрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген анализлау һәм аларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссарына йөкләргә (килешү буенча).

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Х. Ахметов.**

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«____» _______20___ел**
**_________ карарына**
**1 нче кушымта**

**Мөслим муниципаль районы гражданнарын 2020 елда хәрби исәпкә куюны үткәрү буенча төп һәм кабатлаучы составтагы вазифалары күрсәтелгән комиссия составы**

**Төп состав**

| Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме. | Вазыйфасы |
|---|---|
| Гасанов Даҗгын Гаджиага-Углы | Сарман һәм Мөслим районнары хәрби комиссары. Комиссия рәисе |
| Әхмәтов Илнур Хатип улы | Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| Шәмсетдинов Илнар Айрат улы | Мөслим РҮХ өлкән табибы |
| Хаҗиева Разия Гата кызы | Комиссия секретаре, хәрби комиссариат фельдшеры |
| Шәмсетдинов Илнар Айрат улы | Мөслим РҮХ табиб-терапевты |
| Ханов Рөстәм Флүр улы | Мөслим РҮХ табиб-хирургы |
| Сафина Айсылу Нәфис кызы | Мөслим РҮХ стоматологы |
| Гайфиева Динара Әсләх кызы | Мөслим РҮХ табиб-невропатологы |
| Бишимов Тәлгат Нургаз улы | Мөслим РҮХ табиб-психиатры |
| Гайнетдинова Нәкыйбә Гаффар кызы | Мөслим РҮХ табиб-офтальмологы |
| Мустаев Рамил Искәндәр улы | Мөслим РҮХ табиб-отоларингологы |
| Латыпов Илгиз Мәксут улы | Мөслим РҮХ табиб-дерматологы |
| **Резерв состав** | |
| Миңнегулов Камил Нәҗип улы | Бүлек башлыгы (мобилизация ресурсларын әзерләү һәм исәпкә алу билгеләнешен планлаштыру бүлеге) |
| Яббаров Илшат Римас улы | Мөслим районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе |
| Мингазова Ләйсән Алмаз кызы | Мөслим РҮХ өлкән табибы |
| Комиссия секретаре | Комиссия секретаре, хәрби комиссариат фельдшеры |
| Мингазова Ләйсән Алмаз кызы | Мөслим РҮХ табиб-терапевты |
| Ханов Рөстәм Флүр улы | Мөслим РҮХ табиб-хирургы |
| Ахмәтханов Салават.Марс улы. | Мөслим РҮХ стоматологы |
| Ризванова Галина Петр кызы | Сарман РҮХ табиб-невропатологы |
| Измаилова Зөлфия Марат кызы | Сарман РҮХ табиб-психиатры |
| Точилкина Наталья Михайл кызы | Сарман РҮХ табиб-офтальмологы |
| Зиганшин Динар Юлдаш улы | Сарман РҮХ табиб-отоларингологы |
| Абдуллин Шамил Габделхак улы | Сарман РҮХ табиб-дерматологы |

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«____» _______20___ел**
**__________ карарына**
**2 нче кушымта**

**2020 елда 2003 елда туган гражданнарны хәрби исәпкә алу вакытында хәрби хезмәткә чакыру пунктында эшләү өчен шәфкать туташларын бирү исәп-хисабы**

| | **Кем бирә** | **Сан** |
|---|---|---|
| | Балалар поликлиникасы | 3 |
| | «Мөслим РҮХ» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 2 |

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«____» _______20___ел**
**____ карарына**
**3 нче кушымта**

**Хәрби исәпкә куелырга тиешле Мөслим районы гражданнарының медицина тикшеренүе уза торган дәвалау-диагностика учреждениеләре ИСЕМЛЕГЕ:**

1. **Район үзәк хастаханәсе –** армиягә чакырылучыларны гомуми авырулар буенча тикшерү (ПМК, НЦД, ВПС, нефроптоз, сколиоз, хроник пиелонефрит, яссытабанлылык, гипертензия синдромы, баш мие җәрәхәте нәтиҗәләре, хроник отит, ашказаны авыруы, хроник гастрит, велоэргометрия).

2. **Йогышлы авырулар кабинеты –** хәрби хезмәткә чакырылучыларны йогышлы авырулар буенча тикшерү.

3. **РҮХ поликлиникасы –** Мөслим районы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе юлламасы буенча анализлар үткәрү (кан һәм сидекнең гомуми анализы, шикәр авыруын ачыклау өчен, ВИЧка, РВГА кан тапшыру, рентгенологик тикшерү, ЭКГ, УЗИ).

4. **Педиатр кабинеты –** хәрби хезмәткә чакырылучыларны бронхиаль астма, хроник бронхит авырулары буенча тикшерү.

5. **Тире-венерология Кабинеты** – хәрби хезмәткә чакырылучыларны нейродермит, псориаз, витилиго, сифилис, гонорея авырулары буенча тикшерү.

6. **УЗИ кабинеты** – баш һәм муен кан тамырларының ультратавыш допплерографиясе.

7. **Психо-наркология кабинеты** – хәрби хезмәткә чакырылучыларны олигофрения, наркомания, шизофрения авырулары буенча тикшерү.

8. **Табиб-Эндокринолог** – хәрби хезмәткә чакырылучыларны эндокринологик авырулар буенча тикшерү.

9. **Туберкулезга каршы кабинет** – призывникларны туберкулез авыруын ачыклау буенча тикшерү.

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**«____»  _______20___ел**
**_______ карарына**
**4 нче кушымта**

**2020 елда 2003 елда туган гражданнарны хәрби исәпкә алу пунктында эшләү өчен Сарман һәм Мөслим районнары профотборының штаттан тыш ТӨРКЕМЕ:**

**Һөнәри сайлап алу төркеме начальнигы - Мостафина Алинә Анатолий кызы**

**Чакырылыш пунктында эшләү өчен профотбор төркеме әгъзалары**

Шәймөхәммәтова Чулпан Мирзаһит Кызы .
Хафизова Гөлнара Рәис Кызы.
Акмалова Раушания Гарифҗан Кызы.